РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ТИМЕРШИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422057, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19 а
тел. (84362) 2-23-23

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТИМЕРШЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422057, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Тимершык авылы, Пионер урамы, 19 а йорт
тел. (84362) 2-23-23

e-mail: Timer.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
07.09.2020

КАРАР
№ 21

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Тимершык авыл җирлеге Советының
2019 нчы елның 25 нче октябрендә
27 нче номерлы карары белән расланган
Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Тимершык авыл җирлеге составына
керүче торак пунктларда гражданнар җыенын
әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы

карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 2019 нчы елның 25 нче октябрендә 27 нче номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә" түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Гражданнар җыены түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

- әлеге торак пункт составына кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча торак пунктта, әгәрдә торак пункт чикләрен үзгәртү башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кучерүгү китерсә;

- муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча;

-әгәр сайлау хокукына ия җирлек халкы 100 дән артык кеше булса, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган җирлектә җирлекнең вәкиллекле органы төзү, аның саны һәм вәкаләтләре вакыты турындагы мәсьәлә буенча;

-муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

-авыл җирлеге составына керүче торак пунктта, муниципаль район чикләрендә, әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

-авыл торак пунктында авыл җирлеге старостасы кандидатурасын тәкъдим итү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

-авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелергә мөмкин;

- муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча;

- җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта, яңа төзелгән җирлек төзү турында халык инициативасын тәкъдим итү максатларында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр аның сайлау хокукына ия халкы саны 300 кешедән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;

-авыл халкының түбән тыгызлыгы булган территориядә яки үтеп керү авыр булган җирлектә урнашкан, әгәр авыл җирлегендә халык саны 100 кешедән дә артмаган булса, җирлекне бетерү мәсьәләсе буенча.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы, авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/timershik адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Тимершык авыл
җирлеге башлыгы

А.Х. Хаҗиев